# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮТАЗЫ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ АКБАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАР № 28

Акбаш ав. «20» декабрь 2024 ел

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең, җирле үзидарәнең даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәте өчен түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү хакында

2003 елның 6 октябрендәге «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында»гы 131-ФЗ санлы Федераль закон, 2004 елның 28 июлендәге «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында»гы 45-ТРЗ санлы Татарстан Республикасы Законы, 2024 елның 30 апрелендәге «Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2018 елның 28 мартындагы «Даими нигездә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы контроль-хисап органнары рәисләренең, муниципаль хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләүгә чыгымнарны формалаштыру нормативлары турында»гы 182 санлы карарына үзгәрешләр кертү хакында»гы Татарстан Республикасы Министрлар кабинетеның 290 санлы карары нигезендә, “Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы “Акбаш авыл җирлеге” муниципаль берәмлек Уставына таянып, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районы Акбаш авыл җирлеге Советы КАРАР ИТТЕ:

1. Акбаш авыл җирлеге Советының 2018 елның 18 маендагы «Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәне раслау хакында»гы 10 санлы карарына түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

1.1. 2 бүлекнең 1 пунктында «12 688» санын «13 323» санына алмаштырырга;

1.2. Нигезләмәнең 2 өлешендәге 6 пунктында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга.;

1.3. Нигезләмәнең 3 бүлегенең 1 пунктындагы 6 пунктчасында «18 процент» сүзләрен «41 процент» сүзләренә алмаштырырга.;

1.4. Нигезләмәгә 1 нче кушымтаны әлеге карарга кушымта нигезендә яңа редакциядә бәян итәргә;

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында бастырып чыгару (https://pravo.tatarstan.ru Элемтә, мәгълүмат технологияләре һәм массакүләм коммуникацияләр өлкәсендә күзәтчелек буенча Федераль хезмәт (Роскомнадзор) тарафыннан 2013 елның 17 декабрендә бирелгән ЭЛ ФС77-60244 санлы массакүләм мәгълүмат чарасы буларак теркәлү турында таныклык) һәм Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составындагы Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының рәсми сайтында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://jutaza.tatarstan.ru/ электрон адресы буенча дәүләт хакимияте һәм җирле үзидарә органнарының бердәм порталы «Рәсми Татарстан» ны урнаштыру юлы белән рәсми рәвештә халыкка игълан итәргә.

3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә һәм 2024 елның 1 июленнән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Акбаш авыл җирлеге башлыгы И.Р.Сәхибуллина

Акбаш авыл җирлеге Советының 2024 елның 20 декабрь 28 санлы санлы карары белән расланган үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы җирле үзидарә депутатларының, сайланулы вазыйфаи затларының, Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлеге муниципаль хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү тәртибе һәм шартлары турындагы нигезләмәгә кушымта

Татарстан Республикасы Ютазы муниципаль районының Акбаш авыл җирлегендә үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы муниципаль берәмлек башлыгын, депутатларны, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затларын акчалата бүләкләү күләмнәре

| Вазыйфалар атамасы | Акчалата бүләкләү күләмнәре (сумнарда) |
|---|---|
| | шәһәр тибындагы бистәләр нигезендә төзелгән авыл һәм шәһәр җирлекләрендә |
| | 12 төркем |
| Муниципаль бермәлек башлыгы | 18 260 |